МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кремлевская ул., д. 9; Казань, 420111
Тел.: (843) 292-92-12; тел./факс: 292-93-51
E-mail: mon@tatar.ru http://www.mon.tatar.ru
ОКПО 00099837, ОГРН 1021602833196
ИНН/КПП 1654002248 / 165501001

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

Кремль урамы, 9 нчы йорт, Казан шәһәре, 420111,
Тел.: (843) 292-92-12; тел./факс: 292-93-51
E-mail: mon@tatar.ru http://www.mon.tatar.ru
ОКПО 00099837, ОГРН 1021602833196
ИНН/КПП 1654002248 / 165501001

25.11.2011 № 13152/11
На № ____________ ________________

Татарстан Республикасы
муниципаль районнары
башкарма комитетларының мәгариф
идарәләре һәм бүлекләре
җитәкчеләренә

Республикакүләм фәнни-гамәли
конференция үткәрү турында

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы югары, махсус урта һәм гомуми урта белем бирү йортларында укучыларны уртак проблемалар буенча тәҗрибә уртаклашуга тарту максатында, гомуми урта (9-11 сыйныфлар), махсус урта һәм югары белем бирү йортларында белем алучыларны **2012 нче елның 21 февралендә** Казан (Идел буе) федераль университеты Филология һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика һәм лингвокультурология кафедрасында уздырылачак **“Татар лингвокультурологиясе: проблемалар һәм перспективалар”** темасына багышланган республикакүләм фәнни-гамәли конференциядә катнашырга чакыра.

Конференциядә бүгенге көндә теоретик һәм гамәли яктан зур әһәмияткә ия булган лингвокультурология, телара бәйләнешләр һәм тәрҗемә мәсьәләләре, этнопсихология һәм социология проблемалары белән шөгыльләнүчеләр катнашыр дип көтелә.

Конференция татар телендә үткәреләчәк.

Конференциядә катнашу өчен гаризаны һәм материалларны 2012 нче елның 30 нчы гыйнварына кадәр җибәрү сорала.

Хатлар өчен адрес: 420021, Казан шәһәре, Татарстан урамы, 2 нче йорт, КФУ, гомуми лингвистика һәм лингвокультурология кафедрасына (конференциягә).

Электрон адрес: 2011kolil@mail.ru

Контактлар өчен телефон: (843) 2926831.

Кушымта: 4 биттә, 1 экз.

Министр урынбасары Г.Т. Минкина

Г.Г. Әхмәдуллина,
292-27-74

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

КАЗАН (ИДЕЛ БУЕ) ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ

ФИЛОЛОГИЯ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

ТӘРҖЕМӘ БЕЛЕМЕ ҺӘМ МӘДӘНИЯТАРА БАГЛАНЫШЛАР БҮЛЕГЕ

ГОМУМИ ЛИНГВИСТИКА ҺӘМ ЛИНГВОКУЛЬТУРОЛОГИЯ КАФЕДРАСЫ

Гомуми урта (9-11 сыйныфлар), махсус урта һәм югары белем бирү йортларында белем алучыларны **2012 елның 21 февралендә** **"Татар лингвокультурологиясе: проблемалар һәм перспективалар"** темасына багышланган III республикакүләм фәнни-гамәли конференциядә катнашырга чакыра.

Конференциядә бүгенге көндә теоретик һәм гамәли яктан зур әһәмияткә ия булган лингвокультурология, телара багланышлар һәм тәрҗемә мәсьәләләре, этнопсихология һәм социология проблемалары белән шөгыльләнүчеләр катнашыр дип көтелә.

**Конференциянең максаты:**

- филология һәм культурология арасында нәтиҗәле диалог булдыру юлларын эзләү;
- филология һәм культурологиянең үзара хезмәттәшлеге нигезендә туган проблемаларны һәм перспективаларны билгеләү;
- аерым фәннәрнең кисешү нокталарын һәм теоретик-методологик аермаларын ачыклау;
- югары, махсус урта һәм гомуми урта белем бирү йортларында укучыларны уртак проблемалар буенча тәҗрибә уртаклашуга тарту.

**Конференция эшендә түбәндәге юнәлешләрдә фикер алышулар уздырылачак:**

- *Татар лингвокультурологиясе мәсьәләләре: теория һәм практика;*
- *Телнең җәмгыять һәм мәдәният белән бәйләнеше;*
- *Телдә милли характерның чагылышы;*
- *Тәрҗемәдә лингвокультурологик проблемалар;*
- *Фольклор теленең этник үзенчәлекләре;*
- *Татар язучылары һәм шагыйрьләренең иҗатында дөнья сурәтенең чагылышы;*
- *Югары (урта махсус) һөнәри белем бирү һәм төбәк мәдәнияте;*
- *Тел берәмлекләренең этимологиясе һәм тарихы;*
- *Лексикография һәм фразеографиядә лингвокультурология проблемалары;*
- *Лексикада милли-мәдәни үзенчәлекләр;*
- *Телдә рухи һәм матди мәдәниятнең чагылышы;*
- *Телара багланышлар нәтиҗәсе буларак алынмалар;*
- *Телләрне чагыштырма планда (татар-инглиз, татар-немец, татар-рус, татар-чуваш, татар-мари, татар-удмурт һ.б) өйрәнү тәҗрибәсе;*
- *Җирле сөйләшләрдә милли менталитетның чагылышы;*
- *Телара багланышларда китапханә, музей һәм театрның роле һ.б.*

Конференция кысаларында түгәрәк өстәлләр, мастер-класслар, тренинглар үткәрү планлаштырыла. Конференциядә катнашучылар өчен мәдәни чаралар да каралган.

Конференция **татар телендә** үткәреләчәк.

Конференциядә катнашу өчен гариза һәм материалларны **30 январь**га кадәр җибәрү сорала.

**Материалларны түбәндәге таләпләр буенча эшләргә:** Times New Roman шрифты, 14 нче кегль, барлык яктан да 2 шәр см поля калдырыла, текст кәгазь бите киңлегендә тигезләнә, абзацлар 1 см эчкә кереп башлана, юллар арасы - 1,5; сылтамалар текст эчендә квадрат җәяләрдә бирелә: [Зәкиев 2005: 67]. Файдаланылган әдәбият исемлеге текст ахырында алфавит

тәртибендә язылa. Текст эчендәге тел материалы, мисаллар бары тик **курсив** белән генә аерылырга тиеш. Материалның күләме **2-3 бит**.

Юл һәм башка чыгымнарны конференциядә катнашучылар үзләре яки юллаган уку йорты күтәрә.

Материалларны почта яки электрон адрес буенча җибәрергә була.

**Хатлар өчен адрес:** 420021, Казан шәһәре, Татарстан урамы, 2 нче йорт, КФУ, гомуми лингвистика һәм лингвокультурология кафедрасына (конференциягә). Кафедра мөдире – филология фәннәре докторы, профессор Рәдиф Рифкатович Җамалетдинов.

**Электрон адрес:** 2011kolil@mail.ru

**Контактлар өчен телефон:** (843) 2926831 (кафедра лаборанты – Хөснуллина Гөлгенә)

*Кушымта 1*

**Гариза үрнәге**

(русча тутырыла, документлар эшләү өчен кирәк)

| | |
|---|---|
| Фамилия, имя, отчество ученика/студента (по паспорту) | |
| Фамилия, имя, отчество научного руководителя (по паспорту) | |
| Адрес, телефон, e- mail | |
| Место учебы (полное название учебного заведения, факультета) | |
| Тема доклада | |
| Форма участия в работе секций (выступление с докладом/ слушатель) | |
| Нуждаетесь ли в технических средствах при чтении доклада? (в каких?) | |
| Требуется ли размещение в Доме студентов (в общежитии)? | |

*Кушымта 2*

**Материалны эшләү үрнәге**

ТАТАР ФРАЗЕОЛОГИЗМНАРЫНДА ТУГАНЛЫК АТАМАЛАРЫ

*Вәлишина С., Әтнә, X сыйныф*

*Җитәкче: Гарифуллина Э.Ш.*

Татар фразеологизмнары телебезнең лексик байлыгын өйрәнү өчен кыйммәтле материал бирәләр. Аларда лексиканың төрле катламнарына караган берәмлекләрне табарга була........

Әдәбият

Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология. – Казан: Хәтер, 1999. – 288 б.

МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ФГАОУ ВПО "КАЗАНСКИЙ (ПРИВОЛЖСКИЙ) ФЕДЕРАЛЬНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ"

ОТДЕЛЕНИЕ ПЕРЕВОДОВЕДЕНИЯ И МЕЖКУЛЬТУРНОЙ КОММУНИКАЦИИ

КАФЕДРА ОБЩЕЙ ЛИНГВИСТИКИ И ЛИНГВОКУЛЬТУРОЛОГИИ

Приглашаем Вас принять участие во
III республиканской научно-практической конференции студентов и учащихся
"ТАТАРСКАЯ ЛИНГВОКУЛЬТУРОЛОГИЯ: ПРОБЛЕМЫ И ПЕРСПЕКТИВЫ",
которая будет проходить **21 февраля 2012 года**
в Институте филологии и искусств Казанского (Приволжского) федерального университета

К участию в работе конференции приглашаются студенты вузов и ссузов, учащиеся 9-11 классов общих средних школ, лицеев и гимназий Республики Татарстан, сфера научных интересов которых связана с теоретико-методологическими проблемами лингвокультурологии, межкультурной коммуникации и переводоведения, этнопсихолинвистики и социолингвистики, имеющими как теоретическое, так и прикладное значение.

**Целями конференции являются:**

- поиск путей налаживания плодотворного диалога между филологией и культурологией;
- обозначение линий размежевания и выявление теоретико-методологических различий дисциплин;
- выявление проблемных полей, взаимодействие в рамках которых позволяет наиболее полно раскрыть возможности междисциплинарного сотрудничества филологии и культурологии;
- приобщение студентов вузов и ссузов, учащихся школ, лицеев и гимназий к общим научным проблемам.

**На обсуждение выносится следующий круг проблем:**

- *Вопросы татарской лингвокультурологии: теория и практика;*
- *Взаимосвязь языка с обществом и культурой;*
- *Отражение национального характера в языке;*
- *Лингвокультурологические проблемы перевода;*
- *Этнические особенности фольклорной лексики;*
- *Отражение языковой картины мира в творчестве татарских писателей и поэтов;*
- *Высшее (среднее) профессиональное образование и региональная культура;*
- *Этимология и история языковых единиц;*
- *Лингвокультурологические аспекты лексикографии и фразеографии;*
- *Национально-культурные особенности лексики;*
- *Отражение в языке духовной и материальной культуры народа;*
- *Отражение в языке изменений и развития общественной культуры;*
- *Опыт сопоставительного изучения языков (татарский-английский, татарский-немецкий, татарский-русский, татарский-чувашский и т.д.);*
- *Отражение национального менталитета в диалектах;*
- *Библиотека, музей, театр как субъекты межкультурной коммуникации и др.*

В рамках конференции предполагается работа круглых столов, мастер-классов, тренингов. Для участников конференции будет предложена культурная программа.

Рабочий язык конференции: **татарский**.

Срок подачи материалов (только на татарском языке) объемом **2-3 страницы** и заявок до **30 января 2012 года.**

**Требования к оформлению материалов:** шрифт Times New Roman, кегль - 14, интервал 1,5; поля 2 см со всех сторон листа; абзацный отступ – 1 см; переносы запрещаются; выравнивание по ширине; в тексте в квадратных скобках указываются фамилия автора (или название книги без автора), год издания, номер страницы по образцу: [Зәкиев 2005: 67]. Перечень литературы в алфавитном порядке в конце статьи; языковой материал выделяется *курсивом*.

К сожалению, оргкомитет конференции не имеет возможности оплатить командировочные расходы участникам.

Материалы отправлять по почте (в бумажном и электронном вариантах) или по электронному адресу.

**Почтовый адрес:** 420021, г.Казань, ул.Татарстан, д.2, КФУ, кафедра общей лингвистики и лингвокультурологии (материал на конференцию). Заведующий кафедрой – доктор филологических наук, профессор Радиф Рифкатович Замалетдинов.

**Электронный адрес:**2011kolil@mail.ru

**Контактный телефон:** (843) 2926831 (секретарь – Хуснуллина Гульгена)

*Приложение 1*

**Образец заявки участника**

| | |
|---|---|
| Фамилия, имя, отчество ученика/студента (по паспорту) | |
| Фамилия, имя, отчество научного руководителя (по паспорту) | |
| Адрес, телефон, e- mail | |
| Место учебы (полное название учебного заведения, факультета) | |
| Тема доклада | |
| Форма участия в работе секций (выступление с докладом/ слушатель) | |
| Нуждаетесь ли в технических средствах при чтении доклада? (в каких?) | |
| Требуется ли размещение в Доме студентов (в общежитии)? | |

*Приложение 2*

**Образец оформления публикации:**

ТАТАР ФРАЗЕОЛОГИЗМНАРЫНДА ТУГАНЛЫК АТАМАЛАРЫ

*Вәлишина С., Әтнә, X сыйныф*

*Җитәкче: Гарифуллина Э.Ш.*

Татар фразеологизмнары телебезнең лексик байлыгын өйрәнү өчен кыйммәтле материал бирәләр. Аларда лексиканың төрле катламнарына караган берәмлекләрне табарга була........

Әдәбият

Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология. – Казан: Хәтер, 1999. -- 288